БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 06 2022 ел № 207

Кулланучылар кооперациясе оешмаларына беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче, ерак авыл торак пунктларында яшәүче җирлек халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 1 өлешендәге 18 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Кулланучылар кооперациясе оешмаларына беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (1 нче кушымта);

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы (2 нче кушымта);

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия турында нигезләмә (3 нче кушымта);

2. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары;

- «Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 маендагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары;

- «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән (2020 елның 20 маендагы 182 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү

тәртибенә өстәмәләр кертү хакында» 2020 елның 20 октябрендәге 304 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары;

- «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән (2020 елның 20 маендагы 182 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 304 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә өстәмәләр кертү хакында» 2021 елның 2 июлендәге 203 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары;

3. 2022 елда әлеге карар «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда әлеге субсидияләрне һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 5 апрелендәге 590 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән аерым шартларны исәпкә алып кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «30» июнендәге
207 номерлы карарына
1 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Субсидияләр бирү турында гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр, хезмәтләр күрсәтүчеләргә, субсидияләр бирүне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү процедурасын, максатларын һәм шартларын билгели.

Субсидияләр кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле (алга таба - оешма) чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында бирелә.

Субсидияләр бирү нәтиҗәсе булып агымдагы финанс елының үткән чорында Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында сәүдә хезмәте күрсәтүнең (күчмә сәүдәнең) ышанычлылыгы (өзлексезлеге) тора, ул түбәндәге нәтиҗәлелек күрсәткечләре ярдәмендә бәяләнә торган:

- зурлыгы ≥ 0,7 булырга тиеш булган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында күчмә сәүдә графигын үтәү коэффициенты;

- зурлыгы 0,7 дән ким һәм 1 дән артык булмаган, күчмә сәүдәнең Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларын колачлау коэффициенты.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында күчмә сәүдә графигын үтәү коэффициенты (Кгр) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Кгр =Qфакт /Qгр ≥0,7,

биредә:

Qфакт - агымдагы елының үткән хисап чорында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында күчмә сәүдәне гамәлгә ашырганда башкарылган урынга чыгуларның факттагы саны;

Qгр - агымдагы елның хисап чорында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында күчмә сәүдәне гамәлгә ашырганда урынга чыгулар саны.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларын күчмә сәүдә белән колачлау коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Ксп =Офакт /Огр,

биредә:

Офакт - агымдагы елның хисап чорында күчмә сәүдә гамәлгә ашырылган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктлары саны;

Огр - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына күчмә сәүдә графигы нигезендә агымдагы елның хисап чорында урынга чыгу каралган авыл торак пунктлары саны.

1.2. Субсидия күләме тотылган чыгымнар суммасыннан чыгып, әмма Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалардан югарырак түгел итеп билгеләнә. Аны билгеләү өчен субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча белешмә-исәп тапшыра.

Бюджет турында карар проектын (бюджет турында карарга үзгәрешләр кертү турында карар проектын) төзегәндә, субсидияләр турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (бердәм портал бүлегендә) урнаштырыла.

1.3. Субсидия чыганагы булып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты тора.

Бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары күчерелгән җирле үзидарә органы булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты - бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче (алга таба - Башкарма комитет) тора.

1.4. Субсидияләр алу хокукына түбәндәге критерийларга җавап бирә торган кулланучылар кооперациясе оешмалары ия:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә теркәлгән юридик зат булып тора;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле кадрлар составы бар;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле матди-техник базага ия.

Субсидияләр бирү шарты булып кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнары булу тора.

1.5. Субсидияләр субсидияләр бирү өчен субсидияләр алучыларны сайлап алу (алга таба - сайлап алу) нәтиҗәләре буенча бирелә. Сайлап алуда җиңүче дип сайлап алуның барлык критерийларына туры килүче һәм сайлап алуда катнашуга заявкасы (тәкъдиме) сайлап алуда катнашуга башка заявкалардан (тәкъдимнәрдән) алдарак килгән сайлап алуда катнашучы танылыла.

## 2. Субсидияләр бирү өчен субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру тәртибе

2.1. Субсидияләр алучыларны субсидияләр бирү өчен сайлап алу, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне (гаризаларны) соратып алу ысулы белән, сайлап алуда катнашучының сайлап алу һәм сайлап алуда катнашуга заявкаларның (алга таба - заявкалар) керү чиратлылыгы критерийларына туры килүеннән чыгып, башкарыла.

2.2. Башкарма комитет аңа бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек вакытта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ baltasi.tatarstan.ru), түбәндәгеләрне күрсәтеп, заявкалар сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны уздыру вакытларын;

сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итә башлау яисә тәмамлау датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Башкарма комитетның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

субсидия бирү нәтиҗәләрен һәм максатларын;

домен исемен һәм (яисә) челтәрдәге адресын һәм (яисә) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 1.4 һәм 2.3 пунктлары һәм әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата критерийларны һәм таләпләрне;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртип нигезендә сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган заявкаларның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кире алу тәртибен, сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кире кайтару тәртибен, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләрне дә билгели торган, сайлап алуда катнашучыларның заявкаларына үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртип нигезендә сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карау һәм бәяләү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга заявкаларны сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибен, аңлатма бирүне башлау һәм тәмамлау датаaларын;

сайлап алуда җиңүче субсидияләр бирү турында килешүгә имза куярга тиешле вакытны;

сайлап алу җиңүчесен килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру датасын, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләү көненнән соң килүче 14 нче календарь көненнән дә соң булмаска тиеш.

2.3. Сайлап алу үткәрү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына сайлап алуда катнашучы туры килергә тиешле сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр:

- сайлап алуда катнашучының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

- сайлап алуда катнашучылар үзгәртеп кору (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка башка юридик зат кушылу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш), ликвидация процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры турында белешмәләр юк;

субсидия алучы чит ил юридик заты булмаска тиеш, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яисә) финанс операцияләр уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган (офшор зоналары) дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затының тулаем алганда катнашу өлеше 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмаска тиеш;

- сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары (Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар) нигезендә, әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан акчалар алырга тиеш түгел;

- сайлап алуда катнашучылар экстремистлык эшчәнлегенә яки террорчылыкка катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралы таратуга катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел.

2.4. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Балтач район Советының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүчегә – Башкарма комитетка әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2.5. Сайлап алуда катнашу өчен кулланучылар кооперациясе оешмасы Башкарма комитетның икътисад һәм фаразлау бүлегенә (алга таба - Бүлек) түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән формада түләү реквизитларын күрсәтеп, беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнар турында белешмәләр

(мәгълүмат) булган исәпләү белән, заявкалар журналында теркәлә торган субсидия бирү (күчерү) турында гаризаны;

б) гамәлгә кую документларының таныкланган күчермәләрен;

в) оешма җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документның таныкланган күчермәсен;

г) салым органы тамгалары булган, эшчәнлекне ике елдан артык гамәлгә ашырган очракта соңгы ике елга һәм соңгы хисап чорына еллык бухгалтерлык хисапларының таныкланган күчермәләрен яисә керемнәрне һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсеннән өземтәне (салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы оешмалар өчен);

д) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта формасы буенча беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп-хисапны;

е) беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү буенча чыгымнарны раслый торган документларның таныкланган күчермәләрен (юл кәгазьләре күчермәләре, ягулык-майлау материаллары сатып алуга накладнойлар, ягулык-майлау материаллары сатып алуга шартнамә, ягулык-майлау материалларын тоту нормаларын раслау турында документ);

ж) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле матди-техник базаның булуын раслый торган документларны: оешма ия булган һәм (яисә) аннан файдаланган техник чара паспортының күчермәсе, оешма ия булган һәм (яисә) аннан файдаланган транспорт чаралары булуны раслый торган оешманың әйләнеш ведомостеннән өземтәләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына күчмә сәүдә графигы;

з) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле кадрлар составының булуын раслый торган документлар: машина йөртүчеләр белән хезмәт шартнамәләре яисә транспорт хезмәтләре күрсәтү турында шартнамәләр күчермәләре;

и) Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана торган форма буенча бирелгән документларда белешмәләрнең дөреслеген тикшерүне оештыруга ризалык.

2.5.1. Сайлап алуда катнашу өчен, кулланучылар кооперациясе оешмасы үз теләге буенча Бүлеккә түбәндәге документларны кертә:

а) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертү турында таныклыкның таныкланган күчермәсен;

б) Россия Федерациясе территориясендә урнашкан урын буенча салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклыкның таныкланган күчермәсен;

в) салым органы тарафыннан бирелгән салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау хакында белешмәне;

г) сайлап алуда катнашуга гариза бирелгәнче 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

д) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә яисә гариза бирелгәнче 5 эш көненнән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән, җитәкчегә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы затка яки оешманың баш бухгалтерына карата бирелгән соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән документларны сайлап алуда катнашучы тапшырмаган очракта, Башкарма комитет аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

## 3. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Бүлек әлеге Тәртипнең 2.5 һәм 2.5.1 пунктларында күрсәтелгән документларны аларны тапшыру көнендә кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссиягә (алга таба - Комиссия) тапшыра.

Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Башкарма комитет карары белән раслана.

Әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән заявкаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә Комиссия кергән заявкаларны карый, заявкалар составында тапшырылган документларны тикшерә, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән критерийларга һәм сайлап алу таләпләренә туры килү-килмәүдән чыгып, заявкаларны һәм заявкалар керүнең чиратлылыгын бәяли, җиңүчене билгели һәм беркетмә формасында субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар чыгара.

Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә субсидия алучыга Бүлек тарафыннан басма чыганакта почта элемтәсе ярдәмендә җибәрелә яисә Комиссиянең тиешле карары кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидия алучының вәкаләтле вәкиле кулына тапшырыла.

Сайлап алуда катнашучының заявкасын карау һәм бәяләү стадиясендә кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 1.4 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

2) конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән сайлап алуда катнашучыларның заявкаларына таләпләргә туры килмәве;

3) сайлап алуда катнашучы биргән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

4) сайлауда катнашучы тарафыннан заявканы заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яисә) вакыттан соң бирү.

Комиссия утырышында рәислек итүченең һәм Комиссия утырышында катнашкан Комиссия әгъзаларының имзалары куелган беркетмә Башкарма комитетның сайлап алуда катнашучыга субсидияләр бирү турында муниципаль хокукый акты проектын әзерләү өчен өч эш көне дәвамында Бүлеккә җибәрелә. Субсидия бирү турында муниципаль хокукый акт басылып чыкканнан соң, Бүлек аны һәм әлеге Тәртипнең 2.5 һәм 2.5.1 пунктларында каралган документларны алга таба әлеге Тәртиптә билгеләнгән вакытта субсидия күчерү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тапшыра.

3.2. Субсидия алучыга субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетында әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамәдә баш тартуның нигезләре күрсәтелә.

Субсидия алучы, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәгән очракта, әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны субсидияләр бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган көннән соң биш көн эчендә кабат тапшырырга хокуклы.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидияләр заявкалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

3.3. Субсидия бирү субсидия алучы белән Башкарма комитет арасында төзелгән кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүне (алга таба - килешү) нигезендәТатарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан тиешле субсидия төре өчен билгеләнгән типлаштырылган формаларга туры китереп гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү, тиешле төр субсидияләр өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы билгеләгән типлаштырылган форма нигезендә басма чыганакта төзелә.

Килешү Башкарма комитетның субсидия бирү турындагы муниципаль хокукый акты басылып чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә төзелә.

3.4. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе;

субсидия алучыга бирелә торган субсидиянең күләме һәм (яисә) исәбе;

субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны үтәүне контрольдә тотуны (мониторинг үткәрүне) гамәлгә ашыру тәртибе;

хисап бирү формасы, вакытлары һәм тәртибе;

субсидияне күчерүнең тәртибе һәм вакытлары (периодлылыгы);

субсидияне, шул исәптән субсидия бирелгән финанс елында файдаланылмаганын, субсидия чараларын (субсидиянең калган өлешен) кире кайтару тәртибе;

килешү нинди вакытка төзелүе;

субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәү, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүченең хокукы, шулай ук муниципаль финанс контроле органнарының Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы;

субсидия алучының субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәү, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче тарафыннан аңа карата тикшерүне, шулай ук муниципаль финанс контроле органнарының Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы;

якларның җаваплылыгы.

Килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яисә бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүчегә әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән бюджет

йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган итеп киметкән очракта, яңа шартлар буенча ризалыкка ирешмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

3.5. Башкарма комитет «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http:/baltasi.tatarstan.ru) килешү төзегәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек вакытта түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала торган заявкаларны карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карауны уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары каралган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән әлеге заявкалар туры килми торган сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

килешү төзелә торган субсидияне алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

3.6. Комиссия субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән алып бер эш көне эчендә Бүлек беркетмәне һәм әлеге Тәртипнең 2.5 һәм 2.5.1 пунктларында күрсәтелгән документларны алга таба әлеге Тәртиптә билгеләнгән вакытта субсидия күчерү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тапшыра.

Субсидия алучыга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидия күчерү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан закон белән билгеләнгән тәртиптә Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган Башкарма комитет счетыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында субсидия алучыга ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килүче 10 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

3.7. Субсидияләр максатчан характерда, түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

Субсидия чыгымнарның түбәндәге юнәлеше буенча чыгымнар өлешен каплауга бирелә - беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл пунктларына китерүгә ягулык-майлау материаллары сатып алу

Субсидияләр алучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан алынган субсидияләр хисабына югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаштыру әйберләрен сатып алганда (китерткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш, чит ил валютасы акчаларын сатып алу тыела.

3.8. Килешү бер ел гамәлдә булу вакыты белән төзелә.

Бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка килешү төзү Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә кабул ителә торган карарларда каралган очракларда гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән килешү һәм аңа үзгәрешләр кертүне яисә аларны өзүне күздә тота торган өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс органы тарафыннан раслана торган типлаштырылган форма нигезендә төзелә.

## 4. Хисап таләпләре

4.1. Субсидия алучы агымдагы елның һәр кварталының соңгы эш көненнән соңга

калмыйча әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләрнең һәм күрсәткечләрнең зурлыкларына ирешү турында һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы билгеләнгән килешүләрнең билгеле бер типлаштырылган формасы буенча Хисап бүлегенә тапшыра.

Башкарма комитет килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү вакытларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

4.2. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә субсидия алу турында еллык хисапны агымдагы финанс елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тапшыра.

5. Субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тотуны (мониторинг үткәрүне) гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылык турында таләпләр

5.1 Субсидияләр алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәү бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче - Башкарма комитет, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә мәҗбүри тикшерү узарга тиеш.

Килешүгә имза куйганда, субсидия алучы бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче тарафыннан аңа карата субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык бирә.

Башкарма комитет һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләренең зурлыгына ирешүдән чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәмамлау фактын (контроль нокта) чагылдыручы вакыйгаларны мониторинглый.

5.2. Субсидияләр бирелгәндә билгеләнгән шартлар Субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче - Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан уздырылган тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар да, шулай ук әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләр һәм күрсәткечләр зурлыгына ирешмәгән очракта, күрсәтелгән фактлар билгеләнгән көннән алып 10 календарь көн эчендә Башкарма комитет субсидия алучыга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына бирелгән субсидияне кире кайтару турында таләп җибәрә.

Субсидияләр бирүне туктату һәм (яисә) субсидияләрне кайтару турында карарны Башкарма комитет кабул итә.

5.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр Балтач муниципаль районы бюджеты кеременә Башкарма комитетның тиешле таләбен алган көннән алып 30 көн эчендә, ләкин агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан Башкарма комитетның Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган шәхси счетына күчерү юлы белән кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрне кире кайтару Россия Федерациясе бюджетларының таләпләрдә күрсәтелгән керемнәре классификациясенең коды һәм реквизитлары буенча башкарыла.

5.4. Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемено ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

5.5. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидия акчалары (субсидиянең калган өлеше) субсидия алучылар тарафыннан Башкарма комитетның Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган шәхси счетына күчерү юлы белән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты табышына субсидияләр бирү максатлары нигезендә файдаланылмаган акчалар күләмендә кире кайтарылырга тиеш.

Башкарма комитетның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештерелгән агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидияләргә ихтыяҗ булу турында карары нигезендә, күрсәтелгән субсидияләрнең калган өлешеннән артмаган күләмдә акчалар чираттагы финанс елында күрсәтелгән субсидияләр бирү максатларына туры килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен элек бирелгән субсидия алучыга кайтарылырга мөмкин. Күрсәтелгән карар кабул ителгәндә тиешле нигезләмәләр килешүгә кертелә.

5.6. Субсидияләр алучылар тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм субсидияләрне максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җаваплы тоталар.

5.7. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән субсидияләрне максатчан файдалануны контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач район
башкарма комитеты җитәкчесе
____________________________ исеменнән
(оешма атамасы)
_____________________нигезендә эш итүче
________________________________

Адрес: _________________________

Субсидия бирү (күчерү) турында
ГАРИЗА

Сездән ____________________________________________________________ күләмендә
(цифрлар һәм сүзләр белән)
беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүегезне (күчерүегезне) сорыйм.

Тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп беркетелә.

Субсидияләрне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм:

Субсидия алучы:____________________________________________________________
ИНН/КПП: ____________________________________________________________
р/с: _________________________________________________________
Банк исеме: _____________________________________________________
корр. счет: ____________________________________________________________
БИК: __________________________________________________________
ОКТМО: ____________________________________________________________
Урнашу урыны адресы: _____________________________________________
Фактта урнашу урыны адресы: _________________________________
Җитәкченең контакт телефоны: _________________________________
E-mail: _________________________________________________________________

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бирелә торган заявка һәм сайлап алуга бәйле башка мәгълүмат турында мәгълүматны бастырып чыгару (урнаштыру) өчен ризалык бирәм.

"____"_________ 20__ ел

Кушымталар:
1) ________________________________________________________________________;
2) ________________________________________________________________________;
3) ________________________________________________________________________;
4) ________________________________________________________________________;
5) ________________________________________________________________________;
6) ________________________________________________________________________;
7) ________________________________________________________________________;
8) ________________________________________________________________________.

Җитәкче _______________________ __________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
Баш бухгалтер ________________________ __________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

*М.У. (булган очракта)*

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп

| Китерү датасы | Транспорт чарасының моделе, маркасы, модификациясе | Транспорт чарасының дәүләт номеры | Китерелә торган продукция исеме | Транспорт чарасының үткән юлы, км. | Ягулык тоту нормасы, л/100 км | Ягулык-майлау материаллары на бәя, сум/л | Ягулык-майлау материаллары чыгымнары, сум (гр5хгр6хгр7)/100 | Чыгымнарның бер өлешен каплауга тиешле сумма, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | Барлыгы | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйбыз:

Җитәкче ______________________ _________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Баш бухгалтер ________________________ __________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

*М.У. (булган очракта)*

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия алу турында хисап

| Оешма | Килешү реквизитлары | Каралган акча, сум | Алынган акча, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Җитәкче ______________________ ________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
Баш бухгалтер _______________________ _________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

*М.У. (булган очракта)*

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «30» июнендәге
207 номерлы карарына
2 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составы

| № т/б | Вазыйфа | Фамилиясе, исеме, атасының исеме |
|---|---|---|
| 1. | Рәис - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | И.С.Галимуллин |
| 2. | Рәис урынбасары - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы | Р. С. Фатыйхов |
| 3. | Секретарь - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлегенең әйдәп баручы белгече | З.М. Яппарова |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 1. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча) | Ф.Р. Нәбиуллин |
| 2. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы | Р.М. Гарифҗанов |
| 4. | Балтач район башкарма комитеты бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы | З.А. Әшрәфҗанова |
| 5. | Иҗтимагый Совет рәисе | Р.А.Тажетдинов |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «30» июнендәге
207 номерлы карарына
3 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә белән кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе билгеләнә (алга таба - Комиссия).

Субсидия бирү Татарстан Республикасы Балтач район Советының тиешле финанс елына һәм план чорына каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы пунктларында яшәүче халыкка өзлексез сәүдә хезмәте күрсәтү проблемасын хәл итү максатыннан бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүчегә – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары

Комиссиянең функцияләре түбәндәгеләр:

- кулланучылар кооперациясе оешмаларына беренче чиратта кирәкле товарларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә заявкалар карауны оештыру;

- күрсәтелгән субсидияне бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

Комиссиянең бурычы булып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл торак пунктларында яшәүче халыкка өзлексез сәүдә хезмәте күрсәтү проблемасын хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны матди стимуллаштыру тора.

3. Комиссиянең эш тәртибе

Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны сайлап алуда катнашучылардан билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

б) сайлап алуда катнашучыларны үз утырышларына чакырырга һәм аларны тыңларга.

Комиссиядә рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары бар.

Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

3) Комиссия утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

4) Комиссия утырышларында рәислек итә;

5) Комиссия утырышлары беркетмәләренә һәм карарына имза куя;

6) үз компетенциясе чикләрендә Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

Комиссия рәисе булмаган очракта, вазыйфаларны Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын уздыру урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

2) Комиссиягә керә торган документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны Комиссия утырышында карау өчен әзерли;

3) Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

4) Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен һәм Комиссия карарын рәсмиләштерә.

Комиссия әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Комиссия утырышында һәм Комиссия карарлары проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

4) сайлап алуда катнашучыларның тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары, заявкалары һәм документлары белән танышалар.

Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

Комиссия карарлары, әгәр анда 4 (дүрт) һәм аннан да күбрәк әгъзалар катнашса һәм утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителсә, тулы хокуклы була.

Комиссия утырышы, әгәр анда катнашсалар, тулы хокуклы булып санала.

Комиссия әгъзалары саны 8 кеше тәшкил итә.

Комиссия утырышлары сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын һәм документларын кабул итүнең билгеләнгән вакыты чыкканнан алып бер эш көне эчендә чыгарыла торган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә уздырыла.

Гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларны чыгара:

- субсидия бирелә торган катнашучыларны билгеләү турында;

- аларга субсидия бирүдән баш тарткан катнашучыларны билгеләү турында.

Комиссия карарлары беркетмә рәвешендә кабул ителә, аңа Комиссия утырышында рәислек итүче һәм Комиссиянең утырышта катнашкан һәр әгъзасы имза куя.

Беркетмә Комиссия утырышын уздырган көнне Комиссиядә рәислек итүче тарафыннан раслана. Беркетмәдә Комиссия утырышын уздыруның датасы, вакыты һәм урыны, катнашкан комиссия әгъзалары турында, заявкалары каралган сайлап алуда катнашучылар турында, аларны кире кагуның сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризалар туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында игълан нигезләмәләрен күрсәтеп, аларны

кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, заявкалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында, килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исемен һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләмен турында мәгълүмат бар.

Беркетмә расланганнан соң өч эш көне дәвамында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының http:/ baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырыла.

Комиссия карары нәтиҗәләре буенча субсидия бирүдән баш тарткан мөрәҗәгать итүчегә заявкалар кире кайтмый һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында саклана.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына йөкләнә.